МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.04.2026 г.Казань № 81/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында» 2023 елның 13 октябрендәге 384/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы нигезендә б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында» 2023 елның 13 октябрендәге 384/2-пр номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2024 елның 17 маендагы 128/2-пр номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән боерык белән расланган Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында нигезләмәдә:

2.1 - 2.4 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссия Министрлык боерыгы белән төзелә. Күрсәтелгән боерык белән Комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, Комиссия рәисе, аның урынбасары,

секретаре билгеләп куела һәм Комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.2. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

а) министрның беренче урынбасары (Комиссия рәисе), министр урынбасары (Комиссия рәисе урынбасары), Министрлыкның кадрлар бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (Комиссия секретаре), Министрлыкның кадрлар бүлегеннән, юридик бүлегеннән, башка бүлекчәләреннән министр тарафыннан билгеләнә торган дәүләт хезмәткәре;

б) Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе һәм (яисә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсе вәкиле;

в) фәнни оешмаларның, һөнәри белем бирү, югары белем бирү мәгариф оешмаларының һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларының эшчәнлеге дәүләт хезмәтенә бәйле вәкиле (вәкилләре).

2.3. Министр Комиссия составына Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет, Министрлыкның башлангыч һөнәр берлеге оешмасы вәкилләрен кертү турында карар кабул итә ала.

2.4. Әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар Комиссия составына министр таләбе нигезендә, тиешле органнар һәм оешмалар белән килештереп, билгеләнгән тәртиптә кертеләләр.»;

3.1 пунктның «а» пунктчасындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәдә каралган дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләрнең дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылуы турында;»;

3.11 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмә нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләр дөрес һәм тулы дип билгеләргә;»;

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясенең күрсәтелгән боерык белән расланган составын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге боерыкның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр М.А. Җәббаров

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2023 елның 13 октябрендәге 384/2-пр номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2026 елның 17 апрелендәге 81/2-пр номерлы боерыгы редакциясендә) расланды

**Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Гарипов Ленар Наил улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары, Комиссия рәисе |
| Мәхмүтов Марсель Азат улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары, Комиссия рәисе урынбасары |
| Сафин Рәнис Илсур улы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы кадрлар бүлегенең әйдәүче белгече, Комиссия секретаре |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Галимҗанов Алмаз Илдус улы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының аудит һәм коррупциягә каршы эш бүлеге башлыгы |
| Кәлимуллин Илнар Ирек улы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының юридик бүлеге башлыгы |
| Хәертдинова Лилия Мөнәвир кызы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының кадрлар бүлеге башлыгы |

| | |
|---|---|
| Белосков<br>Владимир Тимофеевич | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы, «Земля-землица» республика иҗтимагый-сәяси газетасының баш мөхәррире<br>(килешү буенча) |
| Гаязов<br>Рөстәм Камил улы | Идарә башлыгы урынбасары - Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсенең коррупциягә каршы мониторинг бүлеге мөдире<br>(килешү буенча) |
| Гарифуллина<br>Фәридә Галимҗан кызы | Россия Федерациясе агросәнәгать комплексы хезмәткәрләре һөнәр берлегенең Татарстан республика оешмасы рәисе<br>(килешү буенча) |
| Заһидуллина<br>Миләүшә Мөдәрис кызы | «Татарстан Республикасы Аграр яшьләр берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе<br>(килешү буенча) |